РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Большекляринского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Советская, 9,с. Большие Кляри, 422837
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Кариле**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 9,Олы Кариле авылы, 422837,
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001

**3 декабрь 2021 ел** **№4**

# КАРАР

**2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Чаллы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43 нче йорт адресы буенча урнашкан Чаллы авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 13 декабрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Чаллы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Чаллы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Чаллы авылы зират коймасын ремонтлау ( төзелеш материаллары сатып алу);

- Чаллы авылында Ленин, Түгәрәк, Большевиклар,Тукай урамнары эчендәге юлларга вак таш түшәп төзәтү (вак таш ташу, таш салу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Чаллы авылында юлларны кардан чистарту, грейдлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

- Чаллы авылында җәйге чорда территориядәге чүп үләннәрен чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- янгын депосын һәм автоцистернаны тоту (АЦ-40 (131) өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга):

-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1;

-ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов урамы, 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге**
**башлыгы** **Ф.Г. Гарифуллин**